**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 3 июль № 482

г. Казань

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясе турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясе составын.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\482.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 июль, 482 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасының**
**Сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясе (алга таба – Коллегия) Татарстан Республикасы Сатып алулар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) күмәк киңәшмә органы булып тора һәм һәм үз эшен Дәүләт комитетына йөкләнгән бурычлардан чыгып алып бара.

Коллегиянең төп бурычы – Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле иң мөһим мәсьәләләр буенча килешенгән карарлар эшләү.

2. Коллегия Дәүләт комитеты рәисе һәм аның урынбасарлары, «Татарстан Республикасының сатып алуларны үстерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасындагы территориаль органнары вәкилләре, шулай ук фәнни оешмалар вәкилләре составында төзелә.

Коллегия рәисе (алга таба – Рәис) Дәүләт комитеты рәисе булып тора.

3. Коллегиянең шәхси составы һәм андагы тиешле үзгәрешләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

4. Кирәк булган очракларда Коллегия утырышларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, дәүләт оешмалары, фәнни һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләре катнаша ала.

II. Коллегия компетенциясе

5. Коллегия үзенең утырышларында түбәндәгеләрне карап тикшерә:

Татарстан Республикасы заказ бирүчеләре ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алулар өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы заказ бирүчеләре ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алулар өлкәсендә конракт системасын җайга салу чараларын тормышка ашыруга бәйле мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алуларны гамәлгә ашыруга бәйле перспективалы һәм агымдагы мәсьәләләр;

Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алганда Татарстан Республикасы бюджеты акчасын, бюджеттан тыш финанслау чыганакларын һәм Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре акчасын (финанслар белән тәэмин итү чыганакларына бәйсез рәвештә) планлаштыру һәм тоту нәтиҗәлелеген арттыру мәсьәләләре;

Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алулар өлкәсендә намуслы көндәшлекне, аңлаешлылык һәм ачыклыкны үстерү, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу процедураларында катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү мәсьәләләре;

Татарстан Республикасы заказ бирүчеләре ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алуларны гамәлгә ашыру өлкәсендә гамәлдәге икътисадый, хокукый, административ механизмнар нәтиҗәлелеге;

Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алуны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнары, учреждениеләр һәм Татарстан Республикасының башка оешмалары арасындагы үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре;

товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алулар өлкәсендә норматив хокукый актлар проектлары;

иң мөһим мәсьәләләрне үтәү буенча Дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә торган докладлар.

6. Коллегия утырышына Дәүләт комитеты карамагындагы башка мәсьәләләр кертелә ала.

## III. Коллегия утырышларын оештыру

7. Коллегия утырышлары кирәк булган очракта, ләкин кимендә елга бер тапкыр үткәрелә. Утырыш эшендә Коллегия составының яртысыннан күбрәге катнашса, Утырыш хокуклы санала.

8. Коллегия утырышының көн тәртибе, кагыйдә буларак, Рәис раслаган Коллегиянең эш планы нигезендә билгеләнә һәм Коллегия утырышын үткәрү көненә кадәр жиде календарь көннән дә соңга калмыйча Рәис тарафыннан раслана.

9. Коллегия утырышына аның составына кермәгән затларны чакыру Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән билгеләнгән җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе раслаган исемлекләр буенча алты көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

10. Коллегия утырышын Рәис алып бара, ул булмаганда – Рәисне алыштыручы зат. Коллегиянең соңгы нәтиҗәләре Коллегия карары белән рәсмиләштерелә.

11. Рәискә раслауга кертелә торган материалларны үз вакытында һәм сыйфатлы итеп әзерләү, җыю өчен җаваплылык Дәүләт комитеты рәисе урынбасарларына йөкләнә.

12. Коллегия утырышын үткәрү көненә кадәр 10 календарь көн алдан Дәүләт комитеты рәисе урынбасарлары Рәискә раслау өчен үз эченә түбәндәгеләрне алган материалларны кертәләр:

сорау, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр, нигезләмәләрнең асылын бәян итеп, карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча доклад язуы, әгәр материал Дәүләт комитетында эшләми торган Коллегия әгъзасы тарафыннан әзерләнгән булса, Дәүләт комитетының тиешле структур бүлекчәсе бәяләмәсен;

Коллегия утырышының көн тәртибен;

президиум составын;

Коллегия карары проектын;

кирәкле белешмә материаллар (шул исәптән беренчел карап тикшерү нәтиҗәләре турында белешмәләр);

чакырылганнар исемлеге.

13. Коллегия утырышларында карап тикшерү өчен материаллар Дәүләт комитеты белгечләре тарафыннан Дәүләт комитеты рәисе урынбасарларына Коллегия утырышын үткәрүгә кадәр 14 календарь көннән дә соңга калмыйча кертелә.

14. Коллегия утырышын үткәрү көненә кадәр алты календарь көн алдан Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән билгеләнгән җаваплы вазыйфаи зат Коллегия утырышының көн тәртибен һәм карар проектын Коллегия әгъзаларына җибәрә.

15. Коллегия әгъзаларын һәм башка катнашучыларны чакыру, Коллегия утырышын үткәрү турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту өчен җаваплылык Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән билгеләнгән вазыйфаи затка йөкләнә.

16. Коллегия эшчәнлеген оештыру-теник яктан тәэмин итү өчен җаваплылык Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән билгеләнгән җаваплы вазыйфаи затка йөкләнә.

17. Коллегия утырышында катнашучыларны теркәү һәм Коллегия утырышында бүләкләнүчеләрне раслау, бүләкләү процедурасын әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплылылык Дәүләт комитетында кадрлар эшен башкаруны оештыру һәм алып бару өчен җаваплы хезмәткәргә йөкләнә.

18. Коллегия утырышын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы Дәүләт комитеты рәисе урынбасары Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән билгеләнә.

## IV. Коллегия карарлары үтәлешен тикшерүдә тоту

19. Коллегия утырышын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы Дәүләт комитеты рәисе урынбасары Коллегия утырышын үткәргәннән соң өч календарь көн эчендә Коллегия карарын Дәүләт комитеты рәисенә раслауга кертә.

20. Дәүләт комитетында кадрлар эшен башкаруны оештыру һәм алып бару өчен җаваплы вазыйфаи зат Коллегия утырышын үткәргәннән соң җиде календарь көн эчендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Коллегиянең расланган карарын Коллегия әгъзаларына һәм оешмаларга җибәрүне;

Дәүләт комитетының рәсми сайтында Коллегия карарының расланган проектын һәм Коллегия утырышына материалларны урнаштыруны;

үткәрелгән Коллегия утырышы турындагы мәгълүматны массакүләм

мәгълүмат чараларында яктыртуны.

21. Коллегия карарларының үтәлешен тикшерүдә тоту Дәүләт комитетының вазыйфаи затына йөкләнә.

22. Коллегия карарын үтәү вакытларына агымдагы тикшерү Коллегия утырышын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы Дәүләт комитеты рәисе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

23. Карарның үтәлешен тикшерүдә тоту өчен җаваплы затлар Коллегия карарын үтәү вакытларын үтәмәү һәм бозу турында Рәискә җиткерә.

24. Коллегия карарын үтәү вакытын озайту кирәк булган очракта, үтәүче Рәис исеменә мотивлашкан доклад язуын кертә.

F:\KARAR\2015\482-1.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 июль, 482 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясе СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Редько Ольга Андреевна | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе, коллегия рәисе |

Коллегия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Абдуллин Айдар Мансур улы | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары |
| Baһаветдинов Искәндәр Гыймади улы | «Татарстан Республикасының сатып алуларны үстерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры |
| Гайнетдинов Ренат Вагыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улы | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Груничев Александр Станиславович | Федераль антимонополия хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Ротарь Мария Сергеевна | Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры. |

___